Гөлнур Корбанова



# Үемнең көене

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2006

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
К60

**Корбанова Г.Р.**

К60 Уемның куены: Шигырьләр, поэма, балладалар / Гөлнур Корбанова. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — 111 б.
ISBN 5-298-03972-3

Яшь шагыйрә Гөлнур Корбанованың беренче китабына аның лирик-фәлсәфи шигырьләре, поэмасы һәм балладалары тупланды.

ISBN 5-298-03972-3
© Татарстан китап нәшрияты, 2006
© Корбанова Г.Р., 2006



# Җиһаннан
# мин
# җыр
# алган

* * *

Шигырьне сөймәүчеләр бар,
бар — сөйләүчеләр яттан,
ләкин мин үзем шигырьдән
газапның төмен тапкан.

Ачылган хисләр капкасы,
кочагын җәйгән уем.
Уйларымның куенына кил,
дустым, син дә сыен!

* * *

Кышлар китә, кышлар китә
төяп буранын, карын.
Ничәнче кышны озатам...
Ничәү калгандыр тагын?

Язлар килә, язлар килә,
янә чәчкәдә сирень.
Күпме язлар каршыладым...
Күпмесен көтеп йөрим.

Кыш та, яз да бер-бер артлы
торалар шулай үтеп,
кышлар, язлар — әллә ничә,
гомер генә бер бөртек.

## КҮЗЛӘР

Күзләр — күңел көзгеседер,
күпме сер бар аларда.
Аңлау өчен кешеләрне
кирәк күзгә карарга.

Балкыса бәхет кояшы
күңел күгендә әгәр,
шатлык-сөенеч нурлары
күзләрдән сирпеләләр.

Йөрәкләрдә борчу булса,
сагыш иңә күзләргә.
Таратырга шул сагышны
җитә назлы сүзләр дә.

Күзләр серләре — тирәндә,
йөрәкләргә тоташа.
Эчке дөньяга сукмаклар —
бары тик күзләр аша.

Аңлау өчен күңелләрне,
укыр өчен җан серен,
кирәк бары тик бер нәрсә:
белергә күзләр телен.

## ТАШ ЙӨРӘК

Аһ, белмәдең йөрәгемне,
таш йөрәк, диден юкка.
Ярылыр иде таш булса,
икегә — бер минутта.

Таш булмаса да йөрәгем,
ят түгел миңа ташлар:
басып ташлар өстенә дә
сайрыйлар кайчак кошлар.

Бик булыр идем таш йөрәк...
Ташка таш бәрсәң, дустым,
бөтен дөньяны ялмарлык
сибелеп чыгар... очкын!

## МИН БӘХЕТЛЕ

Мин бәхетле: жан сызланган чакта әгәр
нәни бала кебек үксеп елый алсам.
Йөрәгемнең януларын, ялкыннарын
мин бит елап, күз яшьләрем белән басам.

Бакчаларда кошлар жырын тыңлыйм дисәм,
көзләр житкән, жәйне алып, кошлар киткән.
Әрнүләрдән бушанганчы елыйм дисәм,
күзләремдә әллә инде яшем беткән.

Мин бәхетле: жан сызланган чакта әгәр
бар дөньяны яңгыратып көлә алсам.
Йөрәгемдә булган бетмәс моңнарымны
шул шатлыклы тавышыма күмә алсам.

## БАЛАН

Балан, балан...
Кемнәрнең соң
йөрәк ачыларын алган?
Балан, балан,
мәңге әче булма — баллан!
Кышларын да
бакчаларда ялгыз калган,
язлар көтеп,
коелмыйча түзә һаман.
Баланнарга
сыкы булып яшьме тамган?
Яшь ачырак,
балан әче дию — ялган.
Гомер буе
кызыл бәрхет булып янган,
исеме — баллы,
тормаса да үзе балдан,
балан, балан...

## КУКЕ САГЫШЫ

Кәк-күк! Кәк-күк! Күке була
минем атым,
кешеләргә таралган шул
яманатым.
Мин, имештер, үз баламны
ташлап китәм,
хәлләремне минем кемнәр
аңлар икән?
Бүгенгәчә юк бит минем
жылы оям,
балаларны шуңа башка
йортка куям.
Куям да мин, онытамын —
юк хәтерем,
тапсам эзләп, белер идем,
әй, кадерен!
Дәшәм һаман мин аларга:
«Кәк-күк! Кәк-күк!
Әйтер сүзем минем сезгә
бик күп, бик күп!»
Балаларым эзләп уза
озын көннәр,
минем көнгә калса, сулыр
хәтта гөлләр.
Яшим, ләкин тапмыйм яшәү
кызыгын мин,
гомерләрнең телим сезгә
озынын мин.
Яшим ялгыз. Йөрәгемдә —
күпме сагыш!
Кешеләргә язмасын тик
минем язмыш!

* * *

Бәхетеңне ят күзләрдән
ерак яшер.
Карар бәхетең башкаларга...
Һәм читләшер.

«Мин бәхетле!» — диеп сөрән
салма, тиле!
Өркетерсең — качып китәр,
кайтмас кире.

## СОҢ

Мин гомергә соңарырга
яраттым,
чабышкыдай түгел иде
җан атым.
Төпчек булып тудым җиргә —
тудым соң,
соңлаучыга калган иде
бары моң.
Бәхет кошы калдырган тик
каурыен.
Каурый тоткач язу иде
бар уем.
Соңарудан тора минем
гомерем:
соңлауның да ни икәнен
соң белдем!

* * *

Кайгыларны кара, диләр,
сагышларны — сары.
Аларны акка манардай
ак буяулар бармы?

Авыр, диләр, сагышларны,
кайгыларны — тирән.
Үлчәр өчен юк үлчәүләр.
Үлчәү — йөрәк микән?

* * *

Тәрәзәмне җил кага да,
үзе яшеренә.
Җилнең холкы бала сыман,
олы яше генә.

Әй җилкәем, синең белән
уйный алмыйм качыш.
Уйнар идем, тыен тора
нәкъ егерме баскыч.

## ЯЛГЫЗ АЛМА

Алмагачта — соңгы алма,
җирдә — тәү кар.
Ник өзелми ялгыз алма,
әллә җир тар?

Карлар шундый йомшак кына,
гүя мендәр,
сикереп хәтта йолдызлардан
төшәр көннәр.

Куркытадыр ул алманы,
бәлки, кар-боз?
Салкын карга сыенганчы,
сүнәр ялгыз.

* * *

Дөнья әллә атлар көтүеме?
Дөнья көтә, диләр, күпләрне.
Бер көтүче, бераз ялга диеп,
үләннәргә башын терәде.

Шуны гына көтеп торган сыман,
кушаяклап чапты чаптары.
Мең эзләде, мең тирләде кабат,
тик чаптарын гына тапмады.

...Чаптарларның ярсу чаклары.

* * *

Бәясе бик кыйбат булса да,
бик тәмсез булса да, барыбер
ышанам: яңарыш заманы —
сагынуга бер дару табылыр.

Тизрәк, тизрәк, табиблар,
дәвалый күрегез йөрәгем.
Сез дәва тапканчы, бәлки, мин
сагнудан саргаеп үләрмен.

Оланнар шикелле беркатлы,
нарасый баладай мин үзем.
Ә җилләр көлә дә пышылдый:
«Сагынсаң, сабыр ит, бул түзем».

* * *

Карлар түгел, таулар яуганда да
кар кызыдай сиңа килермен.

«Таулар бит яумыйлар», — дисең син,
хак түгел ул сүзләр син әйткән.
Узыша-узыша бер-берсен,
зур ташлар тәгәри биектән.

Тауларны еламый дисеңме?
Челтерәп бер көмеш юл булып,
чылатып тауларның йөзләрен,
чыгалар чишмәләр ургылып.

Давылның тузанлы яңгыры —
таш-кыя коела биектән.
Тауларның бар җаны! Кешеләр
тауларга сыенган электән.

## ӘЙТСӘМ ӘГӘР

Миләшләрне ачы дисәм,
миләшләрдән дә ачырак
хәсрәтләр бит бар күргәнем.
Җил кызларын җитез дисәм,
беләм җилдән җитезрәк
яшьлегемнең йөгергәнен.

Болытларны биек дисәм,
болытлардан биеккәрәк
күңелемнең бар менгәне.
Дөнья нинди матур дисәм,
дөньядан да матуррак
хыял баскан йөрәгемне.

Диңгезләрне тирән дисәм,
диңгездән дә тирәнрәк
уйларга бар күмелгән чак.
Йөрәк учка сыяр дисәм,
учка сыярлык йөрәктә
моңнар гына кочак-кочак.

* * *

Мин үтәсе бу юллардан
миңа кадәр кем соң узган?
Кем иде ул — күренми дә,
калган бары кубып тузан.

Шул тузанда мин үзем дә
торам әле чак-чак басып.
Юк, тайпылмыйм, китмим читкә,
тузаным да миңа тансык.

* * *

Салават күпере кабынды,
җиде кат, җиде нур, җиде төс.
Җиде кат күпер дә түзмәде,
җимереп, җиңде соң нинди көч?

Дөньяның бусында, ансында
һаман да күперләр, күперләр.
Әйтерсең күпердәй сузылган
безнең дә үтәсе гомерләр.

Салават күпере кабынды.
Карагыз! Кем күреп өлгерде?
Бер очы җирдә бит, бер очы
күкләргә тоташкан түгелме?

* * *

Каләмемне төн яшергән иде,
ак кәгазьне көнем урлаган.
Ә син мине, шигырь, үзең, ахры,
эзләп таптың урау юллардан.

Уй-хисләрем йөгерек саф чишмәдәй
бәреп чыкты ярып тауларны.
Чишмә җырлый хәзер шаккатырып
сандугачлы, җырлы талларны.

Куркытырмын сыман, өркетермен —
кыймый торам аңа дәшергә.
Төннәремне каләм урлый хәзер,
көннәремне кәгазь яшерә.

* * *

Гомерең буена эзләдең
бер киткән бәхетең эзләрен,
тапмадың;
өшегән жанына шул чакта
ятлардан ут алып учак та
якмадың;
һәм «яныйк» дип әйткән кешенең
ачылыр күңеле ишеген
какмадың.
Үттеләр гомерең язлары,
кирәге булмады назлары
ятларның.
Син инде, ашыга-ашыга,
сап-сары көзләрнең каршына
атладың.
Алдында — томан тик, һәм көзең...
Үзеңнең бәхетең син үзең
таптадың.

* * *

Төн.
Ал алмадай кояш өзелгән,
төш юрала күктә без күргән.

Таң.
Безгә таба кояш тәгәри!
Әле якты түгел әллә ни...

Көн.
Ак уйларга күмде безне көн,
чапты вакыт, өзеп тезгенен.

Кич.
Күңелләргә шатлык оялар:
зарыгып көткән җылы оя бар!

Чын.
Төннәр, көннәр, таңнар бер эздән
бер-бер артлы чират тезелгән.

## ДУСКА

Таян миңа, тар булса да
минем җилкәм.
Кирәк чакта була алыр
сиңа җилкән.

Әйт хәсрәтең, яшь булса да
минем күздә.
Уз кайгыбыз булсын әле
үзебезгә.

Хәсрәтеңне ике куллап
янаклармын.
Күмеп куеп, такта белән
кадаклармын.

* * *

Үшәннең эш тозлавы —
эшчәннең теш сызлавы.

## ҖИР ЙОКЫСЫ

Җир тынган. Көз йомып җир йоклый.
Кыш кына урамда, кыш кына.
Төшләрен йокылы дөньяның
бик килә юрыйсы яхшыга!

Яуды кар ишелеп-ишелеп,
бар дөнья юрганга төренде.
Кыш җиргә ак юрган япты да
әнкәем шикелле күренде.

Адашып йөридер ал язлар,
язларга ияреп — шат көнел.
Көннән-көн агара чал кышың,
уян, җир, төш күрер чак түгел.

## И ШАТЛЫК

Ымсындың, ятсындың, тарсындың,
өемә кермәдең син, шатлык.
Өемә кермәсәң кермәссең,
тәрәзне булса да тор шакып!

Яланбаш, яланкул, яланттез
чыгармын йөгереп каршыңа.
Ялынмам, ялвармам, еламам,
«Кер» диеп үтенмәм тамчы да!

Кергәнең юк инде күптәннән,
юксынып зар елый бусага.
Кермәсәң кермәссең, тор әле
ишеккә терәлеп булса да.

## ТЕЛӘМӘ

Ак карлар кебек ак бәхетләр телим сиңа!

*Синең теләктән*

Ак карлардай ак бәхетләр миңа
син теләмә, бер дә теләмә.
Күзен кысып, күктән ак бәхеттәй,
ак тәңкәләр яуган көннәрдә,
кулларымны суздым мин карларга,
булды алар кыска гомерле,
тозлы тамчы сыман бер-бер артлы
учларыма төшеп эреде.

* * *

Битен каплап, бер кызыкай
елый иде беркөн.
«Кайгың нинди?» диеп,
аннан сорамады беркем.

Ул кыз үзе сукыр иде,
сырхау иде тәне,
болытларга поскан иде
яшәвенең яме.

Кызны күреп, күк катында
өзгәләнде тургай.
Тал бөгелде. Кыз үзе дә
нечкә иде талдай.

Тал бөгелде — күтәрмәде
талларның да иңе.
Нәзек талдан нәзек кызый...
Күтәрелгән иде!

«Сукырайган күзләр алар
күрми, —диеп, — берни», —
кемдер шулай сүз аралаш
әйткән иде белми.

Ә кызыкай үз хәсрәтен
күргән инде күптән,
зур кояшны күзлек аша
ул эзләде күктән.

Әнкәседәй шул кояшның тоеп
жылы нурын,
таяк белән капшады да
дәвам итте юлын.

Югалмачы, күк йөзендә
тор син, кояш, балкып!
Әрнеп яткан күңелләрне
нурың белән балкыт!

* * *

Язларым,
язларым,
язларым...
Укыйм мин күкләрнең язганын:
«Гомерләр — бер генә. Язы да,
җәе дә, көзе дә аз аның».

Җәйләрем,
җәйләрем,
җәйләрем...
Җәйләрдә — җиләкле чәйләрем.
Вакытка буйсынып, тын гына
җәйләрне көзләргә бәйләрмен.

Көзләрем,
көзләрем,
көзләрем...
Ни белән тиңлим соң үзләрен?
Көзләрем җимешсез килсәләр,
җимештәй өзелер үзәгем.

Кышларым,
кышларым,
кышларым...
Зәмһәрир суыклы тышларым.
Аңлармын, ни өчен кышларны
калдырып киткәнен кошларның.

* * *

Әй усал яңгыр, син
килдең ник?
Мин сине көтмәгән
идем бит.
Килдең син ашыга,
ашыга,
ниятең түгел тик
яхшыга.
«Чылансын әле бу, —
дисеңдер, —
утында яшеннең
көйсен бер».
Тик миннән көләргә
юк чараң:
соңардың, әй яңгыр,
бичарам.
Заяга тамчыңны
төшермә,
мин инде чыландым
яшемә;
атма син ут-яшен
күкләрдән,
утларда янам мин
күптәннән.
Кичектең шул, яңгыр,
кичектең,
шакыма тәрәзәм,
ишегем:
ачмамын барыбер
бу төндә
мин хәтта йөрәкне
беркемгә!

* * *

Нәкъ минем йөрәктәй
диңгезнең ярлары:
комнарга уелган
эзләрдән яралы.

Тик күпкә җиңелдер
хәлләре ярларның:
ярасын юарлык
дулкыны бар аның.

Дулкыннар, ашыгып,
ярларга ташлана,
ыргыла кыяга,
бәрелә ташларга.

Эзләрне җуя да
юл ала кирегә.
Ә йөрәк сырларын
тигезләр ни генә?..

* * *

«Бәхетле бул» дигән иде
язмышың,
үпкәләттең язмышыңны —
ялгыштың.

Син идең ул гафу сорап
йөгергән,
тик көнче жил эзен сөртеп
өлгергән.

Кул сузасың бәхетеңә
ымсынып,
үксез бәхетең карый сиңа
ятсынып.

* * *

Әйтерсең лә быел суык кышлар
күңелемдә минем кышлады.
Әллә ничек, кинәт жырдан туктап,
тынып калды күңел кошлары.

Кулларыңны куйчы иңнәремә,
кулларыңның тойыйм жылысын.
Берәр мәлгә тәнем генә түгел,
туңган йөрәгем дә жылынсын.

## ӨМЕТ

Яктыдыр йолдыз да, кояш та,
тик Өмет яктырак барсыннан.
Ул барга бәхетем түгәрәк,
күкләрдә тулышкан ай сыман.

Соңгы кат күзләрем йомганчы,
ташлама син мине, Өметем.
Эп-эссе ташларның өстеннән,
ымсынып, артыңнан йөгердем.

Өметем югалткан көннәрдә
арына алмыйча ярсудан
кителә күңелем, кителә,
күктәге артылаш ай сыман.

* * *

Төн йокламый шәлләр бәйли
бер кыз бала,
күз нурлары шәлләренә
үрелеп бара.

Шәльяулыктай киң һәм җептәй
нечкә күңел...
Сүтелүче — әллә йомгак,
әллә гомер.

Төн йокламый шәлләр бәйли
бер кыз бала,
үзе — көләч, ә үзенең
кулы тала.

Мамык шәлен ябынган да
иңнәренә,
«Юк» дип башын чайкый йомшак
мендәренә.

Күрергәме көн туганын
таңга таба,
төн йокламый шәлләр бәйли
бер кыз бала.

## АЧЫШ

Таныш урам. Караңгы төн.
Уйда — курку. Йөгерәмен.
Тибә күкрәк читлекләрен
ватар булып бер йөрәгем.

Күренмимен, гәүдәм каплый
караңгының кара төсе.
Туктап калсам, караңгылык
минем өскә авар төсле.

Чабам-чабам, үзем һаман
сизмим хәлем беткәнен дә.
Яктылыкны узалырлык
көч-гайрәт бар, димәк, миндә.

* * *

Аһ, каеннар, диләр,
ак каеннар, диләр,
сыгылырга әзер
иссәләр дә җилләр.

Ак булмаслар иде:
кеше — усал черки,
суын түгел, аның
канын эчә чөнки.

Ак каеннар ярда...
Аһ, каелган бар да!
Эчсеннәр дә каның,
ак булмыйча кара...

## ШАЯН ШИГЫРЬ

Алпан-тилпән, бата-чума,
салган көйгә
төнлә генә кайтып керде
Гали өйгә.

Хатыны да тирги-тирги
ишек ачты:
— Кайда йөрдең, дуңгыз тәре,
таңга чаклы?!

— Тирги күрмә, ачуланма
мине, җимеш,
мин зиратка бардым, менә
кайтып килеш...

Коелып төште кинәт хатын,
сүзсез калды,
күзләреннән бөртек-бөртек
яше тамды.

— И Ходаем, кем үлгән соң,
нинди кеше?!
— Әй җимешем, үле анда
бөтенесе!

## КУРЧАГЫМ

Бала чакта уйнап туймас
зәңгәр күзле зур курчагым,
җансыз кулың белән бүген
тузгыттың син хис учагын.

Төрә идем биләүләргә,
чәчләреңне тарап үрдем,
мин бит синең әнкәң идем,
инде хәзер түгел беркем.

Инде хәзер түгел беркем...
Күлмәгеңә кунган тузан.
Уйнап чаба-чаба мин дә
була идем синең сыман.

Әллә тузан киткән күмеп,
кайда калган бала чагым?
Елмаюың булып сеңгән
йөзеңәме, әй курчагым.

Бер ваемсыз идем мин дә,
синең төсле көләч идем.
Син һаман шул, син һаман шул,
тик мин генә башка бүген.



Әнкәйле

туган

як

## ӘНКӘЙ!

Озатып кал юлыма карап,
кашыңа куеп кулың.
Карашларың якты бөрки,
караңгы булмас юлым.

Инемә дә кагыл әле!
Әнкәем, синең кулдан
иңнәремә җылы сеңсен —
салкын кышта да туңмам.

## БАЛАН ТӘЛГӘШЛӘРЕ

Түшләремә өзеп кадыйм әле
бакчадагы балан тәлгәшләрен,
бик күптәннән инде, күптәннән юк
баланнарның хәлен белешкәнем.

Балан яфраклары шаулавыннан
бала чакта күпме моңнар оттым.
Уттай янган балан тәлгәшләре
йөрәгеме мин яшәгән йортның?

Яз килдеме? Җанда җырым шытты,
баланнарны түш кесәмә салгач.
Бу күкрәк соң ничек тынып торсын,
берүзендә ике йөрәк янгач?!

## ӘНКӘЙГӘ ХАТ

«Язын кайтам, — дидем, — язын кайтам».
Күп калмады инде язларга.
Тик түзмәдем, әнкәй-бәгърем, сиңа
утырдым мин хатлар язарга.
Кулда — каләм. Тышта — төн карасы.
Коя гына яңгыр иртәдән.
Тәрәзәмне шакыса да яңгыр,
мин булмәмә аны кертәлмәм.
Чылатырга мине телидерме,
агартырга төнне карадан?
Өстәлемдә язган хатым — манма,
чыланырлык җире калмаган...
Йә, ни әйтим, әнкәй, сиңа бүген?
Хәлем изге, синең догаңда.
Юлларымда мине догаң белән
саклый әле изге Ходам да.
Уйларымда бары сагыну гына,
сагыну гына җанны әрнетә.
Сагыш белән тулы төнем минем,
сагыну белән тулы һәр иртә.
Төннәрен дә, әнкәй, яңгыр яуса,
бел син аның яңгыр түгелен:
тәрәз кага дәрвиш-яңгыр булып,
хәлең сорап минем күңелем.

## ИРТӘ

Үләннәргә тамчы-тамчы чык төшкәч,
ай сүндергәч берәм-берәм йолдызын,
кояш нуры энгер-менгер эченнән
каршы ала төн егете таң кызын.

Ә таң кызы — гүзәлләрнең гүзәле!
Төн егете иркә хискә бирелә.
Ә бераздан иртәнге ак томандай
юкка чыга, кочагында эри дә.

Иртә саен кабатлана очрашу.
Бу күрешү — бары тик бер мизгелгә.
Шундый кыска гомерләрнең таңнары!
Кыска шул ул бу гомерләр үзе дә!

* * *

Алма тоткан көләч кызый —
җәй йөгереп узды.
Артыннан җир, еламсырап,
моңлы җырын сузды:

Кыйгак-кыйгак — каз тавышы,
Шыбыр-шыбыр — яңгыр.
Җилләрнең дә шушы көйдә
үз тавышы бардыр.

Әллә соң җәй качкан микән
кырыс көздән юри?
Җилләр кибән асларыннан
җәйне эзләп йөри.

* * *

Су буенда
әнкәйме ул казлар куа?
Ун, егерме...
Саный-саный күз бутала.

«Килегез, кил!» —
һәрбер казын дәшеп ала.
Һич чыкмыйлар
агымсудан казлар ярга.

Әйткән идең:
«Кыз яшьлеге — каз гомере,
вакыт та шул —
терекөмеш кебек тере».

Казлар йөзә...
Ә канатлар — кыйгач-кыйгач.
Мин дә ерак
очтым шулай канат чыккач.

Әнкәй, әгәр
кул изәсәң миңа табан,
казлар кебек
дулкыннарга күмелеп калмам.

* * *

Койды яңгыр.
Бәргәләнеп исте
назлы язның усал җилләре.
Ник бу язлар көзләр кебек икән?
Бу табигать әллә нишләде...

Истә әле,
бүген күргән кебек,
мәгъруР агач җиргә баш игән.
Кошлар җырын пычкы тавышы күмде,
ыңгырашып ауды карт имән.

Истә әле,
язлар килгән чакта,
кыр казларын күктә күргәнем,
шул кошларның барыр юлын бүлде,
моңын кисте угы берәүнең.

Шуңа, ахры,
шуңа тамадыр шул
болытларның керсез яшьләре.
Юк, табигать берни эшләмәгән,
тик кешелек әллә нишләде.

## ИКЕ БӘЙРӘМ

Хушлашканда түгелә телдән
энҗедәй сүз бәйләмнәре:
— Балам, кайчан кайтасың соң?
— Житсен генә бәйрәмнәре.

Яшик әле, әнкәй-бәгърем,
бәйрәм көтеп син дә, мин дә.
Сагынып кайткач, бәйрәм була
сине бары бер күрү дә.

Көтеп алган бәйрәмнәрдә,
әнкәй, кайтып бер әйләнсәм,
бер йөрәккә — ике шатлык,
берүземә — ике бәйрәм.

* * *

Яңгыр ява, һәр көн ява тора —
юып үтә күңел керләрен.
Үзләренчә шаулап сөйлиләр күк
җир йөзенең сихри серләрен.

Яңгыр ява, коеп яңгыр ява,
ә мин торам һаман уйланып.
Җирнең яшерен матурлыгын тойдым
яңгыр асларында чыланып.

* * *

Җәй азагы. Кошлар белән бергә
китеп барыш туган җирләрдән.
Еракларга мондый чакыру хатын
язмыш миңа, язмыш җибәргән.

Бер елыйсы килә, башкаемны
иңнәренә салып талларның.
Талларым да сагыш күтәралмас,
әйтерләр күк: «Нигә калмадың?»

Калмадым шул, нигә калмадым?..

* * *

Сабый чакта татлы җиләк
өзеп ашаттың, әнкәм.
Җиләкнең иң татлысы да
бергә узган шул еллардан
татлырак түгел икән.

Сыйладың әле син тагын
баланнар белән, әнкәм.
Баланның иң ачысы да
аерылудан, аерылудан
ачырак түгел икән.

* * *

Кайтыр кошы кичеккәнме,
каеным никтер боек.
Карадым да шул каенга,
торамын мин дә оеп.

Җырчысын ул кышлар буе
зарыгып көткән иде,
сылу гәүдәсенә язын
яшел күлмәген киде.

Үрелгән дә югарыга,
күзәтә кошлар юлын.
Аның керсез сөюеннән
көнләшеп калган болын.

* * *

Чүп үләне буйлап бара
шундый матур
бер бөҗәк.
Алалмыйча күземне дә
тордым аны
мин күзләп.

Ялтыр-йолтыр килә үзе,
куркытмый да,
чыкмый кот.
Бу табигать ялгышымы?
Үзе матур,
үзе... корт.

## АВЫЛГА КАЙТКАНДАГЫ УЙЛАР

Кайтыр юлым — ерак-ерак,
күктә болыт — кургаш-кургаш.
Аһ, болытлар, мин — ялгызым,
булыгызчы миңа юлдаш.
Сезнең юллар башка якка,
сез капларсыз шәһәр күген,
йә калыгыз ярты юлда,
рәхәт түгел анда бүген.
Зинһар, кире борылыгыз,
анда — сагыну, анда — сагыш.
Менә шуңа түзәлмичә
туган якка кайтып барыш.

Күкләр шулчак күкрәп куйды,
көн киенде кара төстән.
Болытларның юлын кисү
килмәде тик минем көчтән.
Тиргәгәндәй мине болыт,
бер тынды да бер күкрәде,
ишеткәндер аны ул чак
бу дөньяның бик күпләре:
«Туган ягың рәнжеп калган.
Анда — ялгыз әнкәң. Сагыш.
Моны безгә күрү авыр,
шуңа аннан китеп барыш».
Ә болытлар — кургаш-кургаш.
Уйлар гына миңа юлдаш.

* * *

Җир дә, күк тә,
ут та, су да,
бу табигать — бербөтен.
Кояш яна.
Ә болытлар —
кояштан чыккан төтен...

* * *

«Агардылар чәчләрем дә», —
дисең, әнкәм.
Моның өчен, беләм,
безгә юктыр үпкәң.

Синең һәрбер чәч бөртегең
шундый якын.
Көмеш, диләр, чал чәчләрне...
Миңа — алтын.

Алтын? Хәтта алтынны мин
азга саныйм.
Чәчләреңнән көннәремә
ак төс алыйм.

## ГӨЛЛӘР

Гөлләр алар — кеше кебек:
туа, үсә, яши белә.
Гомер көзе житә, шулчак
дөньялардан китә, үлә.

Гөлләр алар нәкъ кешедәй
елый ала, чык — яшьләре.
Күрер өчен гөл хәсрәтен
кирәк бары жан күзләре.

Яумый икән жылы яңгыр,
жылытмаса алтын кояш,
гөлләр шиңә, гөлләр үлә,
яшәеше шулай булгач.

Күзен ачып, чәчәкләр дә
елмаялар зәңгәр күккә.
Әйтәләр күк: «Саумы, тормыш,
мондый бәхет барсын күпкә».

Гөлләр алар кешеләрдәй
сөя-сөелә, сагыналар.
Гөлләр өчен Алла — кояш,
алар аңа табыналар.

Тимә, дустым, син гөлләргә,
соклан бары гөлне өзми,
гөлләргә дә яшәү, гомер
тик бер килә, ике килми.

Аерып алып тамырыннан
куймагызчы вазаларга!
Тели алар табигатьнең
кочагында назланырга.

Чәчәкләрнең һәм гөлләрнең
гомерләре шундый кыска,
ап-ак карлар — ак кәфенлек,
гомер чиге — салкын кышта.

...Гөлләр үсә, яши, үлә.
Шатлыгы бар һәм сагышы.
Кеше кебек яши алар,
һәрбер гөлнең — үз язмышы.

* * *

Тапсын дип биектә үз юлын,
син миңа канатлар биргәнсең,
әнкәем,
кадерлем,
күз нурым...

Тоярга шатлыкның һәрберен
син миңа йөрәк тә биргәнсең,
күз нурым,
әнкәем,
кадерлем...

Тойсам да канатлы икәнем,
йолдызлар мин бүләк итмәдем...
Гафу ит,
күз нурым,
әнкәем...

* * *

Шәһәр тынган, утлар сүнгән
чакларда,
тынгысыз җил һаман карлар
актара.

Тиле сыман коча җансыз
эзләрне,
эзләр буйлап нәрсә генә
эзләве?

Кояш инде йоклый эреп
күптәннән,
җил йокысыз күпме төннәр
үткәргән!

Йоклар иде җырын тыңлап
кошларның,
ләкин җырчы кошы юк шул
кышларның.

Бу төн үтсен, ә аннары,
иртәгә,
үзем җырлыйм бишек җырын
җилләргә!

## КӨЗГЕ УРМАН

Янып торган сукмак буйлап
килдем сиңа, көзге урман.
Хәлең ничек? Каян алдың
шундый матур алтын юрган?

Әллә юмарт көзләр бирде
сихри сары үз бүләген?
Сиңа, урман, бик килешә
көз бүләге — бу күлмәгең.

Чыршы гына гомере буе
салмаганга яшел шәлне
шушы көзге урманда да
хәтерләтә ямьле җәйне.

Талгын җилдә бер чайкалып,
бер тибрәнеп бии миләш.
Ә ак каен әйтерсең лә
туй күлмәге кигән кәләш.

Җырчы кошлар күптән киткән,
серле булып тынган урман.
Җилләр генә кошлар җырын
отып калып җырлый сыман.

Хушлашырга вакыт җиткән,
кайтыр юлга чыктым шулчак.
Урманнарга тагын кил, дип
озатып калды төсле сукмак.

Үз-үзенә сокландырдың,
бирдең миңа шигъри илһам.
Ә хәзергә хуш, исән бул,
рәхмәт сиңа, көзге урман.

* * *

Сузылыплар
үпте болыт
җир-гүзәлне,
гашыйк булып.

Яңгыр койды,
яшен очты,
болыт, шашып,
җирне кочты.

Тынмады һич
төннәр буе
болыт белән
җирнең туе.

...Хәтерләтеп
ак болытны,
ак тузганак
баш калкытты.

* * *

Тәрәз төпләренә гөл утырттың.
Ул гөлләрең, әнкәй, без идек.
Тарсындыкмы якты тәрәзләрне,
җилләр белән җиргә сибелдек.

Сибелдек тә, әнкәй, мин юллардан
танып алдым синең эзләрне.
Уем-буем, бөтен сүзем-үзем
эзләренә шулчак тезләнде.

Тибә бүген уч төбедәй йөрәк,
«Әнкәм-әнкәм» диеп өзлегеп.
Ярты сабак булып ярты җаным
синең янда калган өзелеп.

# САГЫШЛЫ КӨЗ

Көзләр җитте, алтын көзләр,
яфраклар да коела.
Сары көзләр никтер миңа
бик ямансу тоела.

Елак болыт килеп, җиргә
яңгырлар явып үтә.
Кырыс көзләр агачларга
сагышлар бүләк итә.

Агачлардан аера ул
җырчы кошын — тиңдәшен,
һәрбер агач үз җырчысын
сагынмыйча нишләсен?

Сагынудан саргаядыр
ямь-яшел яфраклары,
җәй — аларның яшьлегедер,
ә яз — бала чаклары.

Шуңа күрә алтын көзләр
бик ямансу тоела.
Агачлардан тыныч кына
сары сагыш коела...

* * *

Мин кем икән сиңа, әнкәй,
татлы баланмы?
Әллә алма бакчасында
ачы баланмы?

Шәфәгыңа ямь бирүче
алсу офыкмы?
Әллә томан күмеп киткән
төссез бушлыкмы?

Шатлыгыңмы, кайгыңмы мин,
акмы, караңмы?
Җырыңмы соң, моңыңмы соң,
йөрәк яраңмы?

Күңелеңнең бер кылымы,
өзелгән тартып?
...Кем булсам да, мин бит сиңа
җаныңнан артык.

## ТАҢДА

Серле тынлык. Җилләр генә,
талгын исеп, нидер сөйли.
Гүя алар табигатькә
моңлы бишек көен көйли.

Күзен ачты чәчәкләр дә,
шатлык балкый һәрбер җанда.
Эх, вакытны туктатсам,
калыр идем мәңге таңда!

* * *

Куеныңның җылылыгын, әнкәй,
алыштырмас җылы җәйләрем,
телләремнән еллар юа алмас
син ясаган сөтле чәй тәмен.

Яшер мине җылы кочагыңа,
сагынулар эзләп тапмасын,
йөрәгемне, йөрәк түрләремне
тик сабырлык кына капласын,
сагынуларга урын калмасын.

## КҮБӘЛӘК

Шаяра күбәләк
йорт итеп гөлемне.
Уйнасын, биесен,
бик кыска гомере.

Җилкенә һавада,
җәйләргә куныплар,
канатын чорнаган
минутлар, минутлар.

Көзләрне тойганда
сызамы үзәгең,
әйт әле, күбәләк,
күбәләк-гүзәлем?

## КИЧЕРЕРСЕҢ ӘЛЕ

Ташып чыгып, бер түгелер төсле
күңелемә тулган моңнарым.
Мин — бер карак, җинаятьче бугай:
ул моңнарны күздән урладым.

Чәчәк исле алсу язлардан мин
ашыга-ашыга җыйдым матурлык.
Шуңа күрә күкрәк читлегемдә
явызлыкка артык урын юк.

Кочагың киң, куеның иркен синең.
Гөнаһлылар белән беррәттән
мине шушы караклыгым өчен
кичерерсең әле, Җир-әнкәм.

## САК-СОК ШИГЫРЕ

— Сок туганым! Килә бик тә
күрәсем сине!
Ялгыз газапларның кайчан
булыр соң чиге?
— Әй туганым! Үземнең дә
бәгырем көя,
калды, әнкәебез калды
берүзе өйдә.
— Оч яныма! Сискәндерә
шомлы тавышлар.
— Оча алмыйм! Арабызда
олы каргыш бар.
Күтәрелсәм югарыга,
сына канатым.
— Канатымны ничәнче кат
мин дә канаттым.

Калкып чыга биек булып
нинди тау бу, Сак?
— Булмый калыр иде таулар,
каргыш алмасак!
Телгәләнә безне күреп,
әнкәй йөрәге.
— Нихәл итим, бу язмышны
үзе теләде.
— Җаным түзмәс! Тирә-ягым
калын карурман.
— Язмышлар да безнең кара,
шул урман сыман.
— Юллар тапмый, мин адашып
калырмын беркөн.
— Мин дә булмам, әгәр тавыш
бирмәсә беркем.
— Әнкәебез юкка гына
каргады безне!
— Бездән бәхетлерәк икән
сиам игезе.

* * *

Йөрәгемә сеңеп калган
әнкәемнең бишек җыры.
Бишек җыры, бишек җыры...
Көннәр рәхәт,
көннәр җырлы.

Әнкәй печән чаба кырда,
болыннарда — чалгы җыры.
Чалгы җыры, чалгы җыры...
Көзләр ерак,
җәйләр җылы...

Балачак ул җырлы икән,
балачак ул җылы икән,
бар җылыңны безгә биреп,
туңмадыңмы үзең, әнкәм?

Тик бер кайтып күрер өчен
сабыйлыкның җырлы илен,
җитез аргамаклар җигеп,
еллар буе чабар идем.



# Сөюем сәйләннәре

* * *

Язмышыма рәхмәтле мин,
очраштырды безне.
Сөюләрең, аккош булып,
күзләреңдә йөзде.

Аккошлар бер китә, диләр,
күзләр житсен генә...
Ябып куйчы син аларны
күкрәк читлегенә!

## КАПКА ТӨБЕНДӘ

Төн караңгы. Капка төбе безне
тагын үзенә дәшеп китерде,
тик икебез белгән серләргә дә
бер ул гына шаһит шикелле.

Мәхәббәттән әллә исердек без,
телебездән сүзләр түгелде.
Әкрен яуган ак карлар да безгә
ак чәчәкләр булып күренде.

Кыш салкыны безне куркытмады,
ялкын барда йөрәк түрендә.
Мәхәббәткә жанлы һәйкәл булып
басып тордык капка төбендә.

## МИН СИҢА БАГЫШЛАП ҖЫР ЯЗДЫМ

Мин сиңа багышлап җыр яздым,
сөюем зурлыгын бел шуннан.
Бәлки, бер уфтанып куярсың,
тик инде янында мин булмам.

Булмамдыр ул чакта җирдә дә,
язмышлар ни язган — билгесез!
Тик беләм, оҗмахта йөрсәм дә,
бәхетле булалмам мин синсез.

Мин сиңа багышлап җыр яздым,
наз тулы, яз тулы моңлы җыр.
Күңеленә һич авыр алма син:
бу сиңа аталган соңгы җыр.

* * *

Кудым сине, дидем: «Кит!»
Син ул чакта күңелемә
шундый ерак идең бит.

Китеп бардың. Мин калдым.
Китүең белән йөрәккә
син үтеп керә алдың!

Хәлләр шул ук... Димен: «Кит!»
Яннарымнан түгел, хәзер
җаннарымнан куам тик.

* * *

Син, әйдә, зәңгәр төн бул әле,
мин булам күктәге бер йолдыз;
йолдызлар һәм төн бит гел бергә,
без дә гел янәшә булырбыз.

Йә бул син зәп-зәңгәр күк йөзе,
мин алтын кояшың булырмын;
йә булсам назлы җил, булчы син
шатлыклы көйләре җырымның.

Мин булсам әгәр дә күңелле
шатлыклар өләшкән ямьле яз,
булчы син шул язны тилмереп
көтүче бер җырчы сандугач.

## КЫШ ИНДЕ УРАМДА КҮПТӘННӘН

Кыш инде урамда күптәннән,
кар ятты без йөргән юлларга.
Җанына тынгылык табалмый
шашына нигәдер буран да.

Күкләрдән энҗеләр сибелгән —
ак карлар үбәләр эзләрең.
Көнләшеп карлардан, карлардан
илереп еладым, түзмәдем.

Беләм мин, беләм мин кайтмас һич
ул көннәр — без бергә үткәргән.
Сизмәдем күзләрнең узганын,
кыш инде урамда күптәннән.

* * *

Кышларда — бураннар, бураннар...
Буранга уралган моңнарым.
Кышын мин буранлы бер кичтә
үткәннәр авазын тыңладым.
Хәтерем сукмагын буйладым.
Мин кайттым үткәнгә хыялда.
Сагышым онтылып торды күк
бәхетем яңгыры койганда.
Әле дә янәшә атлый күк
ул гына янымнан, ул гына;
йөрәкләр шуңарга шатлана,
йөрәкләр күкләргә ыргыла.
Бәхеткә килгәндә, белмим мин,
кем ничек аңлыйдыр бәхетне,
ләкин мин үткәнгә кайтуым,
үткәнем белән дә бәхетле.

## ЧИШМӘ

*(Жыр)*

Чишмә, чишмә, әйт әле, син
кай җирләрдән агасың,
таш-кыялар аша узып,
нинди юллар саласың?

Чишмә, чишмә, җавап бирче,
ни турында җырлыйсың?
Әллә син дә, минем кебек,
мәхәббәтне зурлыйсың?

Чишмә, әйтче, яшермәче,
кайда минем үз тиңем;
йөрәк януын басамы
салкын суларың синең?

Чишмә, чишмә, сәлам әйтче
өзелеп сөйгән ярыма;
әйт син тагын: сонламасын,
кайтсын тизрәк яныма.

Челтер-челтер аккан сулар
сәлам әйтерме ярга?
Соравыма җавап бирми,
чишмә ага да ага.

## КАЛДЫР МИНЕ

Калдыр, зинһар, бүген ялгызымны,
шундый рәхәт миңа ялгызым.
Серем сөйләр өчен күктә ай бар,
ә киңәшер өчен — йолдызым.

Беркемне дә күрер теләгем юк,
сөймим хәтта үзем үземне.
Йортын ташлап, акбүз аттай җаным
очар иде өзеп тезгенне.

Йокым качты — әллә алды табып
уйларымның аулак урынын?
Калдыр мине бүген. Ә иртәгә
мин бөтенләй башка булырмын.

* * *

Җыр баласын, җир баласын
гашыйк итте күкләр иле:
тирә-ягың томан гына,
уйларыңда йолдыз иде.

Сөюеңнән канатланып,
күккә таба үрләдең син,
исең китми тапмап уздың
гап-гади җир гөлләрен син.

Йолдызлар шул биек икән...
Ерак йолдыз илләренә.
Гөлең дә юк, йолдызың да,
юлдаш сиңа җилләр генә.

* * *

Ак буранлы кышым! Калдың еракларда...
Син бит минем гомерем язы идең.
Яшьлегемнең аяз таңына син
мәңге бетмәс сөю назы birдең.

Ак буранлы кышым! Мин беләмен шуны:
синдәй кышлар кабатланмас тагын.
Синең карлы буран, салкыннарың
алып килде сөю ялкыннарын.

* * *

Атылдым мин, күп уйламый,
сөюнең кочагына.
Минем өчен сөю үзе
алган да салган иде шул
йөрәген учларына.

Ашыктым ник? (Йөрәкне бит
йодрык кадәрле, диләр.)
Минем өчен йомарланган
йөрәк кебек шул йодрыкны
танымаганмын, җүләр...

## СИН ДӘ ҮЗЕҢ, МИН ДӘ ҮЗЕМ ГЕНӘ

Учак яна чәчеп ялкыннарын,
очкыннарын сибә күк йөзенә.
Үткәргәнсең айлы шушы төнне
син берүзең,
мин дә үзем генә.

Еллар үткәч, учак янып беткәч,
бер чик җиткәч сабыр-түземемә,
ачылырмын, бәлки, җилләргә мин:
«Ул да үзе,
мин дә үзем генә».

Үкендерер, беләм, үкендерер
тыңлаганга кеше сүзен генә.
Һәм белербез сөю ачыларын
син дә үзең,
мин дә үзем генә.

## КИТӘСЕҢ ДӘ ЮГАЛАСЫҢ

Китәсең дә югаласың,
кала эзләрең генә.
Кабат кайтуыңны көтеп,
тала күзләрем генә.

Китәсең дә югаласың
тагын күпмегә шулай?
Көтеп, күзләр генә түгел,
йөрәк тә арый бугай.

Китәсең дә югаласың,
ерак юллар арасы...
Һич югында, бер хәбәр сал,
мин дә адәм баласы.

* * *

Ул көнне мин мәңге онытмам!
Кар коелды
ертык болыттан.

Юл чатында калдык икебез.
«Хуш мәңгегә!
Сау бул!» — дидек без.

Кыш эндәште безгә ул көнне:
«Сукыр бәхет
кирәк түгелме?»

Еламаска теләп, мин көлдем,
ак карларга
ялгыз күмелдем.

Ак теләкләр телә юлыма!
Һәм озатсын
мине юл гына!

## ЗАРЛАНМА

Һәр көн саен берьялгызың
чишмәләргә киләсең.
«Сөйгән ярым ташлады», — дип,
күз яшеңне түгәсең.

Зарланма әле дөньядан,
зарланмачы, әй сеңел.
Күрче, дөнья нинди матур,
зарланыр вакыт түгел.

Парлыларны күрсәң әгәр,
үзәкләрең өзелә.
Һәрнәрсәнең үз чиге бар —
син хәзергә түз генә.

Зарланма әле дөньядан,
зарланмачы, әй сеңел.
Уйнап-көлеп, җырлап-биеп,
шаулап үтсен яшь гомер.

Син һаман да аны уйлап
кибәсең, саргаясың.
«Яшәү бигрәк төссез», — диеп,
дөньядан зарланасың.

Зарланма әле дөньядан,
зарланмачы, әй сеңел.
Яшьлегең шау чәчәк ата,
зарланыр чагың түгел,
зарланмале, әй сеңел!

* * *

Күңелемдә йөрткән сүзләремне
син тутырып алдың кушучлап.
Учлап кына алма әле, әйдә,
әйтер сүзләр миндә бер кочак.

Сүзләрем бар, татлы хыялларым...
Хыялланмый түзеп буламы?
Иңнәреңә синең тотынам да
күтәреләм сыман югары.

Синең гомер әле яшәлмәгән,
үтелмәгән күпме юлларың.
Юлың — борма. Учың төбендәге
сызыклары сыман кулларның.

Хәвеф-хәтәр сине читләп узсын,
ә бәхетең булсын ягымлы.
Барыр юлың якты булсын диеп,
миләш тәлгәшләре кабынды.

* * *

Күзләремдә — синең шәүлә,
йөрәгемдә — синең исем,
күңелемдә — сөю хисем,
син бит минем яшәү көчем.

Күзләреңдә — минем шәүлә,
йөрәгеңдә — минем исем,
күңелеңдә — сөю хисең,
рәхмәт сиңа барсы өчен.

* * *

Күрдеңме син җәй узганын,
юмартлыгын кояшның?
Җәйләремне син үзең дә
шатлыкларга буяштың.

Тып та тып шаян алмалар
бакчаларда биеште.
Алсу иде киемнәре,
биюләре — килешле.

Хәзер инде ак томанлы
көзләр уята иртән.
Җәйләрем җырга булса да
әйләнеп кайтса икән!

* * *

«Чын сөюең алда әле, — диләр, —
сагышланма, — диләр, — кыз бала!
Көрче әнә, кышкы бураннарда
агачлар да сынмый, төз кала.

Буран тынгач, кышкы табигатьтә
ямьле көннәр итә хакимлек.
Тормышның да шундый икәненә
ышана бел әле иң элек».

Ләкин белмим минем тормышымда
бураннарның кайчан үтәсен.
Гомер агышында тынмый торган
бураннар да була, күрәсең.

* * *

Сагыш болыты килде дә
каплады яшьлек күген.
Юлдаш миңа тик сөюем...
Ялгыз мин, ялгыз бүген.

Шигырь энҗеләре булып,
хисләрем чыксын ташып!
Бу — соңгы яратуымдыр
тилереп, янып, шашып.

Сиздерməскə генə телим,
өзгәләнә бит күңел...
Син китсәң дә, сөю калды,
юк, мин һич ялгыз түгел!

* * *

Хисләремне тыя алмый,
моңнарына кушып язның,
чын йөрәктән сиңа атап,
кабатланмас җырлар яздым.

Ә җырларым, ул җырларым
сиңа бирни түгел иде.
Китеп алар синнән читкә,
болытларга барып инде.

Сиңа дигән җырларымны
үз итмәде бөдрә болыт,
һәм кабаттан чәчләреңә
яуды алар карлар булып.

## СУ БИРСӘНӘ

Су бирсәнә, су бирсәнә,
көя бәгырем, көя.
Җанга учлап-учлап утлы
күмер салганнар гүя.

Йә алып бар чишмәгә,
чишмә, бәлки, ял бирәлер
янып арган хисләргә.

Су бирсәнә, су бирсәнә,
тик кирәкми күз яшең.
Кызганма да, әйтмә дә син:
«Түзгәнсең, — дип, — түзәрсең».

Авыр хәлләрем, авыр.
Яндым, янам, янармын, һәм
гөлдән көл генә калыр.

* * *

Язлардан соң башым җуеп йөргән идем:
«Тора, — диеп, — дөнья тоташ салкыннардан».
Җылы җәйләр килеп мине үзгәрттеме?
Бирде мәллә кабат сөю хакын Аллам?

Җанда сүнгән учак янә кабынганга,
шулай эссе булды мәллә узган җәйләр?
Җәйләр генә түгел, ике күңел кылын,
өзелмәслек, ныклы итеп, сөю бәйләр.

Синле җәйләр генә мине үзгәрткәндер,
арынды күк дөньям коры салкыннардан.
Җәйләрдән соң башым җуеп йөрим хәзер:
«Тора, — диеп, — яшәү тоташ ялкыннардан».

* * *

> Син дә суга ташланмыйсың,
> мин дә ташланмыйм аңа.
> Йөгерәбез яр буенча,
> тик якынаймый ара.
>
> *Ф.Яруллин*

Тирән елга үргә ага
ярсып-ярсып,
син — бер ярда, мин бер ярда
тордык басып.

Кавышулар, күрешүләр
безгә тансык,
иңнәремә асылташтай
сөю асып,

ташландым мин биек ярдан
ташкын суга,
батып калды ләкин асыл
ташым суда.

Йотып эчкә, зур елганы
кичтем көчкә,
яр ишелер төсле иде
минем өскә.

Сүндерде су сөю утын
йөрәктәге,
очрашулар миңа инде
кирәкмәде...

* * *

Күрдем дә күз аттым, яраттым,
атылдым биеккә-биеккә.
Җир-анам калды тик аһ орып,
мин очтым, кош гүя — киңлеккә.

Юлларда канатым канаттым,
яшеннәр уйнатты күзләрен,
тик һаман өметем өзмичә,
наз тулы язларны эзләдем.

Күрдем дә — яраттым. Ә хәзер
куркытмый кышлар да, көзләр дә.
Никадәр эзләгән язларны
мин таптым тик синең күзләрдә.

* * *

Чаба алга житез тимер атым,
озыная бара чакрымнарым.
Кулым болгап, тәү һәм соң кат сине
чакрымнарым аша чакырмамын.

Чаба атым, тояк эзләренә
тулып кала татлы хыялларым.
Әверелсен алар йолдызларга,
мин аларны инде җыялмамын.

Чакрымнарым ераклашкан саен,
ерагая бара күңелләрем.
Язгы болыт булып кайтмам сиңа,
ләйсән яңгыр булып түгелмәмен.

* * *

«Син минем иң назлы гөлем, — дип
кагылма, кагылма кулларга.
Күрәмен, хисләрең ялган бит,
беләм мин энәле булсам да.

«Син минем иң татлы гөлем», — дип
үрелмә, үрелмә үбәргә.
Йөрәге бозланган яр өчен
тиңдер мин агулы гөлләргә.

Килмә дә! Барыбер үтмәбез
бу тормыш юлларын бергәләп.
Мин чәчкә икәнмен, син — гөлдән
гөлләргә очучы күбәләк.

## ЙӨРӘК

Сүнәр-сүнмәс учакка мин
сөюемне аттым учлап.
Ялкынлана-ялкынлана
күтәрелде күккә учак.

Кочак-кочак сөюемне
елгаларга салдым өеп.
Суы кайнап, елга кипте,
яры калды кара көеп.

Учак янып көлгә калды,
яргаланып кипте инеш.
Барыннан да ныграк янып,
йөрәк калган исән килеш.

* * *

Күрәсеңме,
җибәрергә сине теләмичә,
миннән китәргә — ерак юлларга,
хәлләремне минем аңлагандай,
аягыңа томан урала.

Беләсеңме,
күктә кояш әнә ничек балкый,
җир изрәгән җылы нурына.
Алтын нурларыннан үреп, кояш
пәрдә элгән барыр юлыңа.

Сизәсеңме,
китмәс борын әле, яшь аралаш,
сагыну хисләремне кузгатып,
аерылырга синнән теләмичә,
һаман барам сине озатып.

## КЫШЛАР КЕБЕК

Карлар яуган. Җир төренгән
ак мамык юрганына.
Сөенәм мин бу дөньяда,
бәгърем, син булганына.

Бөтен дөнья, бар җир йөзе
ак кар белән капланган.
Шул карлардай безнең сөю
ак булганга шатланам.

Шатланам мамык карларга,
сөенәм матур кышка.
Кышлар кебек, безнең сөю
булмасын гына кыска.

* * *

Мин сиңа чәчәкләр
сузамын — ал гына,
алкышлар яңгыры
яуса да алдыңа.

Мин үзем бер тамчы
йөзләрдән, меңнәрдән,
болытка уралып
күкләргә меналмам.

Ялкынлы сулышың
битемә тидерден.
Үптең дә битемнән,
көнләште иренем.

* * *

«Тунгансың» дип, кулларымны түгел,
жылыталсаң жылыт йөрәкне.
Җирдә миңа, тәннекеннән бигрәк,
жылылыгы жанның кирәкле.

Ашыкма да кышны гаепләргә.
(Сокланмас соң кышка кем генә?)
Йөрәгемә кышлар түгел минем,
заманалар салкын тын өрә.

* * *

Исемеңне жырларыма куштым,
тыялмадым ярсу күңелне,
исемеңнән жырым-шигырьләрем
шул минутта нурга күмелде;
шифасымы булды исемеңнең —
күптән сулган гөлләр терелде.

## ЮАТМА

Җырны күмгән язмыш көлүләре,
сагышларга җаннар уралган.
Син юатма мине,
мин барыбер
элеккедәй шаян булалмам.

Юатмачы. Җылы сүзләреңнән
бар дөньямны янә моң баса.
Дәшми генә тыңла елавымны
йә бер тиргәп ташла, булмаса.

Тормыш офыклары — тоташ томан,
томаннарда юллар югалган.
Юатмачы мине,
мин барыбер
элеккедәй шаян булалмам.

* * *

Киттең...
Шомлы тынлык күмде
аяк тавышының соңгысын.
Күмсен әйдә,
килә әле минем
тынлыкны да бераз тыңлыйсым.

Киттең...
Өйгә сүзсез, төссез
бушлык керде атлап бусагам.
Бу көнелем дала гөле мәллә,
бушлыкка да хәтта сусаган.

* * *

Хатларыңны ягарга дип
күтәрелсә кулым,
кулларымны гафу итмәс
хатлардагы моңың.

Алар миңа гомер буе
белдерерләр үпкә.
Алар тирәсендә минем
моңнар көчсез күпкә.

Хатларыңны һаман саклыйм,
ишет әле, ишет.
Ертып утка аталмамын,
ташлый алмам кисеп.

* * *

Ялгыш кына күзләремә бактың,
керфекләрдә калдың адашып.
Ә күзләрем минем якты иде,
адашыплар һич тә калмаслык.

«Кояшым бул, — диден, — көннәремдә,
төнемдә бул айдай ягымлы».
Күк йөзендә ай-кояшка таба
ак болыттай хыял агылды.

Ялгыш кына күзләренә бактым,
хыялыңда калдым адашып.
Ә хыялың шундый якты иде!
Адашыплар һич тә калмаслык.

* * *

Бәгырькәең ташмы? Әллә синең
йөрәгеңне кармы каплаган?
Нинди салкынсың син! Ә мин — юләр!
Салкын кояшка да шатланам.

Сүзең салкын. Үзең, карашларың
тундырырлык эссе чөлләрдә!
Йә әйт бер сүз, бары бер җылы сүз,
«Яратам» дип, телең җәлләмә.

Хәл ителсен безнең аралар да,
йә дөрләсен, йә гел суынсын.
Хисем кайнар калыр. Аларны бар
суытырлык нинди суык соң?

* * *

Синең белән узган минутларым
кадерлерәк тулы гомердән.
Син кабызган йөрәк хисләремә
мин ятларның кулын тидермәм.

Беләсеңдер, без аерылганга инде
айлар түгел, еллар узганын.
Күңелдәге синең рәсемгә тик
кундырмадым вакыт тузанын.

Офтанмыйм мин, үткән сөю өчен
уздырганга гомерем моңаеп,
кая барсам күз алдымнан китми,
син торасың һаман елмаеп.

* * *

Сагынасыңмы?
Юктыр...
Янәшәңдә
әнә күпме гөлдәй ярлар бар.
Минем генә
иләсләнгән җаным
тик көзгедән үзенә табар пар.

Сөясеңме?
Юктыр...
Тирәңдә бит
«Сөям» диючеләр нихәтле!
Миңа бүген
тик кайтаваз гына:
«Мин яратам сине!» — дип әйтте.

## МӘҢГЕЛЕККӘ КИТЕП БАРЫШЫМ

Аерылышу — әллә синең язмыш,
әллә инде минем ялгышым?
Үз җанымны кыйный-кыйный,
синнән мәңгелеккә китеп барышым.

Гөлләр кебек, сөю корыганда
күтәралмый язлар каргышын,
ярты җаным ярты юлда кала,
мәңгелеккә китеп барышым.

Юлларыма, күңелемә төйнәп
алдым бары сөю сагышын.
Озат мине, әйдә, соң мәртәбә...
Мәңгелеккә китеп барышым.

* * *

Бик күрәсем килгәч сине,
үзем эзләп килдем.
«Үткәннәргә юллар юк бит,
килмә бүтән», — диден.

Нихәл итим, юл юклыгын
мин үзем дә беләм.
Көләр чакта елап яшим,
мең үкенеч белән.

Килмәсәм дә, мин кайтырмын
уйларына урап.
Һәм китәрмен күңелеңнен
тынычлыгын урлап.

Нигә генә була алмый
килмә дигән сүзен
йөрәгемә — йөгән минем,
тезләремә — тезген?

* * *

Сине күрдем. Бу беренче тапкыр
шашынуы иде йөрәкнең.
Ул вакытта шундый яшь идем мин,
син янарга мине өйрәттең.

Син дә яндың. Гүя кояш үзе
күкрәк читлегендә балкыды.
Китә алмам синнән — чыга алмам
сөю елгалары аркылы.

Сине күрдем. Бу бит соң мәртәбә
шашынуы иде йөрәкнең.
Гомерем буе сүрелмәслек итеп,
син сөяргә мине өйрәттең.

* * *

Ярым булсаң, ярам гына булма,
салма үкенечле көннәргә.
Кояш нуры белән җылы янгыр
көтеп яши һәрчак гөлләр дә.

Акыл түгел, бары киңәш булсын
минем сиңа шушы кушканнар.
Нинди игезәк сүзләр: «Ярым», «Ярам»
һәм үзара нинди дошманнар!

## СИРЕНЬ ЧӘЧӘКЛӘРЕ

Сирень чәчәкләре бүләк иттен,
мин исердем аның исеннән.
Сиреннәнме, әллә сөюдәнме,
кайсыннан соң идем исергән?

Мин — бер яры, син — икенче яры
сөю дигән ярсу елганың,
уйласам да синле һәм сиреньле
язлар булыр диеп елларым,

аерылдык инде. Минем кебек
яныл көйде күптән сиреньнәр.
Бер очрашсак, элеккедәй итеп
елмайсыннар гына иреннәр.

Сирень чәчәкләре бүләк иттең.
Мин исердем аның исеннән.
Кемдер тагын шундый гөлләр сузса,
юк инде, мин кабат исермәм.

* * *

Мин бит сине, әй, хәләлем,
хыялымнан әвәләдем!

Әвәләгәч шаклар каттым,
шундук сине мин яраттым.

Күңелемә (табып юлын)
сандугачтай килеп кундың.

Курыккандай судан, уттан,
чынбарлыктан нигә куркам?

Сөюемне, әй, сөйгәнем,
сиңа әле бер сөйләрмен.

* * *

Саубуллаштың: «Китәм бүген,
хуш инде!»
Юлларың ап-ак иделәр —
кыш иде.

Хәбәр салдың: «Сагынуларга
түз инде!»
Без утырткан миләшләргә
көз инде.

Әйләнде дә килде озын
җәйләрем,
ул җәйләрне тагын ялгыз
җәйләдем.

Бүген миннән көлә кебек
язларым,
язларыма жырым белән
язамын:

«Кайтыр дигән хыялларым
буш инде.
Синле уйларымнан китәм...
Хуш инде!»

* * *

Дөньяның бер үги кызы сыман,
ялгызлыктан җаным кыйнала.
Син, ялгызлык, бераз шәфкатьле бул,
кыйнамале җанны, кыйнама!

Кагылырга кыйма күңелемә,
өзелергә тора күңелем.
Оныттылыйм дием, учларыма
утлы чагын кыстым күмернең.

Гомерләрем җәйгә авышканда,
алтын түгел, көмеш көннәрдә
җаным һаман сөю базарында,
җәйләремнән язлар теләнә.

* * *

Әй, бәгырь!
Күңелгә якынсың нигәдер.

Ымсынам:
хыялым бер сиңа кул сузган.

Карашың гел миңа,
тик миңа карасын!

Сүнәм дә
терелəм ышанып сүзләргә.

Әй, каһәр!
Йөрәккә якынсың шулкадәр...

## ЗӘҢГӘР КАПКА

Без урамда идек икәү.
Каршыда — зәңгәр капка.
Зәңгәр капка безнең өчен
торган җилләрдән сакта.

Зәңгәр капка, зәңгәр капка,
бирмә ярымны ятка!

Карыйм-карыйм, күз алалмыйм,
борылып, син киткән якка.
Төсен, безнең сөю сыман,
югалткан зәңгәр капка.

Зәңгәр капка, зәңгәр капка,
нигә буялдың акка?

Минем өчен күңелең күптән
капкадай бикле чакта,
үз-үземне ышандырып,
ник кętәм сине чатта?

Зәңгәр капка, зәңгәр капка,
калды шул ярым ятка.

* * *

Кешеләргә була жан аткан чак,
күңел кайткан чак та.
Әгәр сиңа тартылса жан, аны
кире борма, сакла!

Кире борма. Синең тарафыңа
очкан күңел кошым,
күзләрдә дә китмәс булып, мәңге
синдә оя корсын.

Кеше жаны, бәлки, гомер буе
сусау мәрхәмәткә?
Күр, кояшка елмаялар әнә
язын гөлләр хәтта.

Мин килермен, жылы сорап, тагын,
бәлки, эссе жәйдә.
Һәм калырмын жаныңа ук күчеп
синдә бөтенләйгә!

* * *

Син иден — йолдызлар иленнән.
Күрдең дә җирдәге яз кызын,
әлиһә танымый син миндә:
«Күкләргә мен», — диеп кул суздың.

Җир миңа тар иде. Шуңадыр,
борылып карамый артыма,
кулыңа тотынып атылдым
күкләрнең меңенче катына.

Җилкенчәк күңелем уйнады
болындай күкләрдә тәгәрәп.
Яшь, ярсу тай идем мин әллә —
килде соң кайлардан ул халәт?

Ярыштым канатлы кош белән,
ярыштым ябышып җилләргә.
Сүзләрең калдылар озатып:
«Әй, кызый, җилләргә иярмә!»

Ак болыт алды да кочаклап,
сыендым иңенә болытның.
Ерактан авазың ишеттем:
«Йолдызың барлыгын оныттың...»

Күкрәде күкләр дә. Болытлар
кайнады, сибелде яшене.
Һәм мине томандай болытым
төсенең агына яшерде.

Диңгездәй фирүзә күгемдә
хыялым әйләнде корабка,
хыялга утырып, хушлашмый,
мин киттем еракка-еракка.

Түзмәсәм яшенле күкрәүгә,
кабаттан мин моңлы җыр булып,
күкләрдән, яралы кош сыман,
учыңа төшәрмен егылып.

## БУЛ ГЫНА

Мин сине көзләрдә саргайтмам,
калдырмам язларда ялгызың,
кышларын өшетмәм, туңдырмам,
бул гына, бул минем язмышым.

Күмәрмен бәхетнең нурына,
син минем язмышым бул гына.

Тормышта ялгызың авыр ул,
кошлар да булдыра оясын.
Гел балкып яшәргә теләсәң,
бул гына, бул минем кояшым.

Күмәрмен сөюнең нурына,
син минем кояшым бул гына.

Парлашсын җирдәге гашыйклар,
каерылган канатлар булмасын.
Син минем икенче сыңарым,
бул гына, бул гомер юлдашым.

Күмәрмен бәхетнең нурына,
син минем юлдашым бул гына.

## СҮЗ

Бар дөньямны үзгәртергә
җитте синең тик бер сүзең.
Син бу гомер, шул сүзеңне
әйтми торып, ничек түздең?

Син ул сүзне әйткәч, булды
карлы кышлар җиткән сыман.
Инде кабат тереләлмам:
хыял чикле. Канат сынган.

Басып торам гүя бөтен
йөрәгемне урлаткандай.
Гүя өмет офыгында
сүнгән кояш, югалган ай.

## РОМАШКА

Ромашка җыйдым да кулыма,
өзгәлим чәчәкнең канатын.
Таҗ саен һаман да бер үк сүз:
«Ярата, яратты, яратыр».

Чәчәкнең таҗлары үпкәләп,
сибелеп калдылар эзләргә.
Ник өздем кояштай гөлләрне?..
Бик ерак бит әле көзләргә.

Ромашка чәчәге барыбер
өзелә, өзелде, өзелер...
Күңелем үзе дә өзелгән
ромашка чәчәге төслеләр.

* * *

Киләчәгем якты юл иде,
шатлыклар да анда мул иде,
башка юллар таптым,
шунда учак яктым,
язмыш язганнары шул иде.

Күзләрең дә синең мут иде,
йөрәккәең тулы ут иде,
күңелеңә бактым,
актарыплар аттым,
мин эзләгән якты юк иде.

Мин эзләмим хәзер яктылык,
яктылыгым булсын — ак болыт.

* * *

Ят кочакка тартыласың,
бүлмәм барыр юлыңны.
Тик анда сине минем күк
яратучы булырмы?

Ят учакка тартыласың,
эзлисең җылы, ялкын.
Сиңа минем ялкын түгел,
ятлар салкыны якын.

* * *

Син үзең дә беләсеңдер
көтүләрнең газабын,
кайчан гына тоярмын соң
шул газапның азагын?

Уйлама син: «Көтә, — диеп, —
карап тәрәзгә таба».
Мин түгел ул, алсу гөлем
тәрәзгә шулай бага.

Зәңгәр күзле гөлләр булып,
мин инде сине күптән
тәрәзәгә карап түгел,
юлга ук чыгып көтәм.

* * *

Минем сиңа атап язган
гүзәл җырым бар иде.
Ул җырга синең йөрәктә
никтер урын тар иде.

Сөю көюгә әйләнде,
җырым әйләнде моңга.
Ул моңны җилләр китерсә,
тыңла тын калып, тыңла!

Эзләреңә сүзсез генә
баш иялләр гөлләрем.
Йөрәгемдә сөю йөрттем,
тик син генә белмәдең.

## КӨНЛӘШЕРСЕҢ

Ялгыз гына керәм бүген
төннең кочагына.
Ә син, беләм, көнләшерсең
төнне кочканыма.

Шаша-шаша сарылыр да
тезләремә дулкын,
каерып бәйләрдәй булырсың
дулкыннарның кулын.

Чәчләремне тузгытыр җил,
үбәр назлап аннан,
син көнләрсең җилләрдән дә,
калмас түзәр чаман.

Тынгы бирмәс көнләшүдән
булыйм дисәң азат,
ялгызлыкның куенына
китмә мине ташлап!

* * *

Безгә карап әйтте берәү:
«Пар аккош», — дип.
Ә без булдык синең белән
Сак һәм Сок тик.

Агачтагы пар алмага
тиңләделәр.
Өзеп алды миннән аерып,
сине кемнәр?

Охшаттылар безне тагын
йолдыз-айга.
Мин ай булсам, син — кояш шул
әллә кайда.

Әллә кемнәр, әллә нигә
тиңләп безне,
безгә түгел, мәхәббәткә
күз тигезде!

# Поэма, балладалар



## ГАРМУН МОҢЫ

*(Баллада)*

Өй эченнән бер көй ишетелә —
талгын гына гармун моңнары.
Йөрәкләргә үтеп керә ул моң,
тибрәндереп күңел кылларын.

Салмак кына бер җыр көйли гармун,
әкрен чыга көмеш тавышы.
Юк, көйләми! Елый икән бит ул,
гармун моңы — гармун сагышы.

Әрнеп шыңшый гармун: кайтмады бит
үз хуҗасы сугыш кырыннан.
Исән чакта егет гармункаен
бер төшерми иде кулыннан:

каз өмәсе, аулак өйләр, туйлар —
һәр бәйрәмдә гармун көйләре.
Иң беренче түргә гармун менде,
үз теләндә көйләр көйләде.

Парлаштырып кыз һәм егетләрне
ул биетте яшьлек вальсына;
сөюләргә шаһит булды гармун,
сокландылар аның тавышына.

Яуга киткәндә дә тирә-юньдә
гармун көе тынып тормады,
шул гармунын кочып, соң мәртәбә
егет шушы җырны җырлады:

«Исән булсам, бер кайтырмын әле,
сез, туганнар, мине көтегез.
Җиңү килер. Гармун тавышыннан
гөрләп торыр тагын өебез».

Ничә җәйләр үтте. Көзе, кышы...
Әйләнде дә килде язлары.
Җиңү килде. Киткән кошлар кайтты,
тик гармунчы гына кайтмады.

Гармун көтә әле: егет кайтыр,
кочып алыр, сөртер тузанын.
Җыр агылыр оныттырыр сыман
гомерләрнең җырсыз узганын.

Гармун саклый моңлы күңелендә
язмышына олы бер үпкә:
үзе белән бергә картаерга
насыйп булмады ла егеткә!

Ятып калган егет җилкәләрен
сагынучы — гармун гынамы?..
Юатыр сүз тапмыйм ятимнәрне,
юатыр сүз тапмыйм толларны.

Туктагандай гармун тавышлары
өзелгәндер егет гомере...
...Гармун тынды. Гүя серен сөйләп,
бушаныплар калды күңеле.

Ятим гармун, ничә еллар үткәч,
моңайды да ятлар кулында,
һәм җырлады өзелеп моңсу җырын —
кайтмый калган солдат турында.

# СОҢЛАМА

*(Баллада)*

**1**

Авыл читендәге бер урамда,
иң кечкенә
жыйнак бер йортта,
ничә еллар буе
ут сүндерми
улын көтә ялгыз бер карчык.
Көтә әле,
өметләре аның
мәңге сүнмәс учак шикелле:
менә беркөн улы кайтып керер,
киң итеп ачар ишекне.
Үзалдына ул сөйләнеп куя,
эндәшә дә тыныч бушлыкка:
«Юлга чыксаң,
исән йөр син, балам,
хәвефләргә берүк юлыкма.
Син кайтырсың әле,
беләм, улым.
Ашыга күр, берүк соңлама.
Вакыт житкәч,
кеше китә жирдән.
Без мәңгелек түгел дөньяда.
Бер саескан хәбәр бирен узды —
кайтуыңа синең юрадым».
Улы өчен һаман саклый ана
жылы хисен,
авыр уйларын.
«Тик йөрәгем генә хәлдән тайган.
Син кайтканчы диеп
бераз гомер сорыйм Алладан».

Ялгызлыкка әле дә түзгән ана —
еллар буе улы кайтмаган.
Хәтерли дә карчык яшьлек чагын,
калтыранып куя шул көннән:
үзе ята — сырхау, ут эчендә,
ә сабые — юеш киемнән.
Бер йотым су кирәк!
Бер тамчы су!
Иреннәрнең дымы калмады.
Бер тамчы хәл —
һәм баласын ана
бишегеннән алыр аннары.
Актык көчен җыеп
торып басты.
Алды улын кайнар кочакка.
Уттай янган авыру тәнгә урап,
кием киптерде ул шул чакта.

## 2

...Бер саескан хәбәр биреп узды.
Төн — йолдызлы шәлен ябулы.
Хәл белергә кергән иптәш сыман,
тәрәзәгә төште ай нуры.
Ишекне соң кем шакыды килеп?
Эшсез йөргән әллә җил иде —
сискәнде дә карчык шул тавышка,
тәрәзәгә барып иелде.
Күзләре дә сукырая барган,
бик зарыккан ана, нишләсен —
улы кайткан диеп белде,
танымады
айдан төшкән үзенең шәүләсен:
«Син кайттыңмы, бәгърем,
балакаем,
озак көттем сине мин, улым.

Тукта
хәзер
үзем ишек ачам!
Әй газизем минем, күз нурым.
Синең кайту — шатлык.
Бәлки инде
калмагандыр озак яшисем.
Ялгыз итмә тагын мине, балам,
иштәсеңме?
Нигә дәшмисең?»
Ике кулын сузып
ауды карчык,
кочакларга теләп шәүләсен.
Чү, син, җирем!
Ак мамыкка әйлән!!!
Имгәтәсең ана гәүдәсен.
Тешен кысып, җилләр тынып калды,
ай ялгышын тоеп үкседе,
күкләр өчен, бөтен җиһан өчен
ялгыз карчык шундый үз иде...
Иртәгесен ачы хәбәр китте
авылдагы барча халыкка:
«Авыл читендәге бер урамда,
иң кечкенә жыйнак бер йортта,
өй янында
җирдә карчык ята,
йөзләре ак, тәне суынган».
Күрше-күлән шунда таба чапты,
малаена хәбәр сугылган:

«Әнкәң сүнгән.
Тизрәк кайт, бала!
Син мәңгегә инде соңлагансың!!!
Соңгы мәртәбә дә соңлама!»

# ЧИТЛЕК

*(Поэма)*

## 1

Төннәр авыр. Төннәрдән дә бигрәк,
кургаш кебек авыр тоела көн.
Төннәр белән көннәр авырлыгын
аңлар иде микән берәр кем?

Бу якларда җылы яңгыр түгел,
кайнар тамчы тама болыттан.
Тулган ай да монда, тулган ай да
кайчан булганлыгын оныткан.

Читлек кебек төрмә сакта тора,
чәнечкеле күзен зур ачып.
Китеп булса, һәркем китәр иде
җәһәннәмгә хәтта үк качып.

Качып кара! Саклап тора әнә
мылтык тоткан солдат баласы.
Коймасы да шактый озын икән,
үткәрәсе еллар чамасы.

Көннәр үтә. Зур читлектә тагын
тыз-быз килеп кайный хатын-кыз.
Һәркем монда — укылмаган китап,
мең үкенеч монда, мең язмыш.

## 2

Зилә инде бу йортына
ияләшеп бара.
Яше кипкәч, әйтте беркөн
язмышына: «Яра».

Белсә дә шул алачагын
ул кулларын өтеп,
кул бирде ул язмышына
килешкәндәй итеп.

Тешен кысып, якты көнен
көтә хәзер Зилә.
Эше бетсә, авыр уйдан
тагын башын ия.

**3**

«Кызым, кызым, син— алтыным,
шаярасың яткан килеш,
бер минут та тик тормыйсың,
алтын түгел, терекөмеш.

Кызым, кызым, күбәләгем,
кояшым син, түгәрәгем,
балдан татлы бал алмам син,
якты нурдан яралган син».

Әй сөенә Зилә. Кызын
сөя үзе, сөеп туймый.
Әле куян булып кача,
әле кәҗә булып уйный.

Күкрәгенә кыса кызын,
«Йом күзеңне, — диеп, — бәбкәм,
кояш инде күптән сүнгән,
озакламас, кайтыр әткәң».

Һәм нәниен кочкан килеш
өйдә якты төшен күрә.
Уяна да тышка карый —
ачылгандай була келә.

Күңелен янә калтырата
салкын ятак, ялгыз төннәр.
Үз хуҗасын көтә сыман
хәтта изелмәгән мендәр.

Шикле көнчеллекме, нидер
чеметеп ала керсез җанны,
ул бит шулай ничәнче кат
каршылады ялгыз таңны.

**4**

Өстәлдәге чәй дә салкын,
инде күптән аш суынган,
гүя берни булмагандай,
ире кайтты таң алдыннан.

Әйтте шунда бичәсенә,
ташлады да гамьсез караш:
«Тагын эшләр килеп туды,
эштән чыкмый бит минем баш».

Зилә тагын кабат-кабат
сорашмады аның хәлен,
шөбһәләрен куды читкә,
ябынды да зәңгәр шәлен.

**5**

Керде беркөн күрше хатын,
бар белгәнен салды тезеп:
«Таудай уйлар миндә, күрше,
тора алмыйм бүтән түзеп.

Белмисеңме, әллә үзең
сиздерергә теләмисең,
көтә-көтә җанашыңны
сары булып кипкән йөзең.

Син яшисең сабыр итеп,
яшь агызып бушанасың,
хыянәтнең барлыгына
килмәсә дә ышанасың,

әйтәм сиңа мин турысын:
ят куенда синең иптәш.
Икесе бергә күңел ача,
шунда бара эше беткәч.

Сүзләремнән терелсә дә
җан бирергә яткан шигең,
мин бит хаклы. Синең җанаш
ачты башка йортның биген».

Әйтте дә тиз чыгып китте,
тынды камчылаган тавыш.
Зилә шәмдәй басып калды,
котсыз уйлар белән ялгыз.

**6**

Күктә тагын ай кабынды.
Озыная киче көзнең.
Ул ышанып ирен көтә,
тәрәзәдән алмый күзен.

Җир себерен җилләр йөри,
туза яфрак бураннары.
Җилдә өйгә юлны тапмый
адашканмы әллә ярый?

Адашмаган, йөри генә
ике юлның сайлап берсен.
...Авыр сулап, йолдыз кызы
борылды да япты йөзен.

Күпме көтәр иде Зилә,
Өзелмәсә әгәр тезген?
Каты куллы шиге дулап,
якасыннан тотты үзен:

«Ышанмасаң әгәр миңа,
үзең барып кара, иптәш!
Мәйданында киң күңелнең
тынсын безнең озын көрәш».

Зилә сихерләнгән сыман,
тоймады да киенгәнен,
төннең каршысына чапты,
көчкә җыеп актык хәлен.

Килеп керде шикле йортка,
ә ятакта... ире аның.
Янында кем? Көндәшеме?
«Яратуың шулмы, җаным?!

Мин бит сине көтә-көтә
үткәргәндә ялгыз төннәр,
синең кайнар кочагыңа
сыенган бит әнә кемнәр.

Мәңгелеккә бүген бастың
йөрәгемнең янганын син,
кичер, ләкин күтәралмыйм
хыянәт һәм ялганны мин».

Кинәт шунда нидер булды —
җир убылды әллә шулчак,
яшен кебек җемелдәде
өстәлдәге очлы пычак.

Тавыш тынган. Ә Зиләнең
кулларында канлы хәнҗәр.
...Көндәшенең күзләренә
салкын тынын өрде әҗәл.

## 7

Хәнҗәр үзе озынайган!
Бу җинаять
ул куллардан түгел! Абау!
Канатларын каерып кысты
каты богау.

Кычкырдылар: «Бер сүз сөйләшмәскә!
Карамаска артка, як-якка,
тимер биек ишекләргә кадәр!
Куллар артта!

Әйдә, тиз атла!
Син — тоткын!
Язмышыңның тәмуг бакчасыннан
ачы алма йоттың».

Ябылдылар ыңгырашып
тимер ишек, тимер челтәр.
Ватып кына чыгар иде —
кайда икән тимерчеләр?

Ишекләргә бик эленде,
язмышлардай авыр йозак.
Шалтыраган ачкыч чыңы
янгырап торды озак-озак.

## 8

Башка сеңгән казый сүзе:
«Уникe ел төрмә... Төрмә!»
Тар кабер дә яхшырактыр,
кирәк түгел мондый тирмә.

Көнме? Төнме? Аерылмый.
Кызы читтә. Өе ерак.
Тавышлары карлыкканчы
бәргәләнде Зилә елап:

«Коткарыгыз мине моннан,
таш та бетон тирә-ягым.
Ташлар миңа туган түгел,
яралмаган таштан җаным.

Коткарыгыз! Сабыема
ана назы бирү өчен.
Җан алучы мин түгел ул,
мин түгел, ул — минем үчем.

Инне баса дымлы һава,
күтәрергә җитмәс көчем!»
Тик берәү дә тыңламады,
ишетмәде аның сүзен.

Тимер өстәл, тимер түшәк,
сакчылар да — бар да тимер.
Тимер читлек эчендә бит
тимердән дә авыр гомер.

## 9

Төштә генә калдымыни,
ымсындыра ирек, ирек!
Үзе тора янда гына,
үзе кояш сыман биек.

Ашыгыгыз сез, минутлар,
тизрәк бул, вакыт, вакыт!
Борылып артка карамый да,
их, очарга канат кагып!

Кош теледәй хатлар гына
аралардан йөри урап.
Хатлар әле, шөкер, армый,
булсалар да юллар ерак.

Менә бүген Зиләгә хат
тәүге тапкыр — күз нурыннан.
Туңган куллар эреп китә
шушы хатның жылысыннан.

«Әни, әни! Исәнме син, әнием!
Еракларадан сәлам жибәрәм.
Хаталарым булса, гафу ит син,
мин язарга әле өйрәнәм.

Бу көзләрдә мин мәктәпкә кердем
беренче кат — тәүге сыйныфка,
тик йөрәкнең генә эче поша,
хафалана янда син юкка.

Син, тиз генә кайта алмыйм, дисең,
тирә-ягым, дисең, тимердән.
Бер син генә түгел әле, әнием,
сине сагынып мин дә тилмерәм.

Әти эштән бик еш соңлап кайта,
йә кайтмый да кала кайчакта.
Шулчак сиңа сыенасым килә,
зинһар, әнием, кайтып кочакла».

## 10

«Кайгырма,
түз бераз, акыллым,
мин монда мәңгегә килмәдем,
беркөнне көз белән кайтырмын.

Тимер бик
иреккә чыгаргач берзаман,
икәүләп китәрбез еракка,
корырбыз ояны яңадан.

Әтиең...
Ул инде ят миңа бөтенләй.
Сөюем калмады — янды да
каралтты йөземне төтендәй.

Әтиең...
Ул сине житәкләп,
каршымнан узгандай була да
тузанлы, томанлы юлларда
сукмагын табалмый югала.

Мин кайтсам,
кайтырмын көзләрдә яз булып.
Тик миңа сабый чагың түгел,
яшьлегең төбәлер ятсынып.

«Тимер кан!» —
үткәнем, киләчәк, бүгенге...
Шул даным каршыңа басса да,
югалтма кояшлы күгеңне!
Көт мине!»

## ЭЧТӘЛЕК

### Җиһаннан мин җыр алган

«Шигырьне сөймәүчеләр бар...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 4
«Кышлар китә, кышлар китә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 4
Күзләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Таш йөрәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Мин бәхетле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Балан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Күке сагышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
«Бәхетеңне ят күзләрдән...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Соң . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
«Кайгыларны кара, диләр...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
«Тәрәзәмне җил кага да...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Ялгыз алма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
«Дөнья әллә атлар көтүеме?..» . . . . . . . . . . . . . . . . 11
«Бәясе бик кыйбат булса да...» . . . . . . . . . . . . . . . . 12
«Таулар бит яумыйлар...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Әйтсәм әгәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
«Мин үтәсе бу юллардан...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
«Салават күпере кабынды...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
«Каләмемне төн яшергән иде...» . . . . . . . . . . . . . . . . 14
«Гомерең буена эзләдең...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
«Төн...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Дуска . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
«Үшәннең эш тозлавы...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Җир йокысы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
И шатлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Теләмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
«Битен каплап, бер кызыкай...» . . . . . . . . . . . . . . . . 19
«Язларым...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
«Әй усал яңгыр, син...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21
«Нәкъ минем йөрәктәй...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
«Бәхетле бул» дигән иде...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
«Әйтерсең лә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Өмет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
«Төн йокламый шәлләр бәйли...» . . . . . . . . . . . . . . . . 25

Ачыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
«Аһ, каеннар, диләр...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Шаян шигырь . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 27
Курчагым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28

**Әнкәйле туган як**

Әнкәй! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
Балан тәлгәшләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
Әнкәйгә хат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
Иртә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
«Алма тоткан көләч кызый...» . . . . . . . . . . . . . . 32
«Су буенда...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
«Койды яңгыр...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Ике бәйрәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
«Яңгыр ява, һәр көн ява тора...» . . . . . . . . . . . . 35
«Җәй азагы...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
«Сабый чакта татлы җиләк...» . . . . . . . . . . . . . . 36
«Кайтыр кошы кичеккәнме...» . . . . . . . . . . . . . . 37
«Чүп үләне буйлап бара...» . . . . . . . . . . . . . . . 37
Авылга кайткандагы уйлар . . . . . . . . . . . . . . . 38
«Җир дә, күк тә ...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39
«Агардылар чәчләрем дә...» . . . . . . . . . . . . . . 39
Гөлләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
«Тапсын дип биектә үз юлын...» . . . . . . . . . . . . 41
«Шәһәр тынган, утлар сүнгән...» . . . . . . . . . . . . 42
Көзге урман. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
«Сузылыплар...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
«Тәрәз төпләренә гөл утырттың...» . . . . . . . . . . . 44
Сагышлы көз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
«Мин кем икән сиңа, әнкәй...» . . . . . . . . . . . . . 46
Таңда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46
«Куеныңның җылылыгын, әнкәй...» . . . . . . . . . . . 47
Күбәләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 47
Кичерерсең әле. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
Сак-Сок шигыре. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
«Йөрәгемә сеңеп калган...». . . . . . . . . . . . . . . 50

**Сөюем сәйләннәре**

«Язмышыма рәхмәтле мин...» . . . . . . . . . . . . . . 52
Капка төбендә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 52
Мин сиңа багышлап җыр яздым . . . . . . . . . . . . 53
«Кудым сине, дидем...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
«Син, әйдә, зәңгәр төн бул әле...» . . . . . . . . . . . 54

Кыш инде урамда күптәннән . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
«Кышларда — бураннар, бураннар...» . . . . . . . . . . . . . 55
Чишмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
Калдыр мине . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
«Җыр баласын, җир баласын...» . . . . . . . . . . . . . . . 57
«Ак буранлы кышым!..» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
«Атылдым мин, күп уйламый...» . . . . . . . . . . . . . . 58
Син дә үзең, мин дә үзем генә. . . . . . . . . . . . . . . 59
Китәсең дә югаласың. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 60
«Ул көнне мин мәңге онытмам!..» . . . . . . . . . . . . . 61
Зарланма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62
«Күңелемдә йөрткән сүзләремне...» . . . . . . . . . . . . 63
«Күзләремдә — синең шәүлә...» . . . . . . . . . . . . . . 64
«Күрдеңме син җәй узганын...» . . . . . . . . . . . . . . 64
«Чын сөюең алда әле...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 65
«Сагыш болыты килде дә...» . . . . . . . . . . . . . . . . 65
«Хисләремне тыя алмый...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
Су бирсәнә. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
«Язлардан соң башым җуеп йөргән идем...» . . . . . . . . . . . 68
«Тирән елга үргә ага...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 69
«Күрдем дә күз аттым, яраттым...» . . . . . . . . . . . . 70
«Чаба алга җитез тимер атым...» . . . . . . . . . . . . . 70
«Син минем иң назлы гөлем», — дип...» . . . . . . . . . . . 71
Йөрәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
«Күрәсеңме...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
Кышлар кебек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
«Мин сиңа чәчәкләр...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73
«Тунгансың» дип, кулларымны түгел...» . . . . . . . . . . . 73
«Исемеңне җырларыма куштым...». . . . . . . . . . . . . . 74
Юатма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74
«Киттең...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
«Хатларыңны ягарга дип...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
«Ялгыш кына күзләремә бактың...» . . . . . . . . . . . . . 76
«Бәгырькәең ташмы?...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
«Синең белән узган минутларым...» . . . . . . . . . . . . 77
«Сагынасыңмы?..» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
Мәңгелеккә китеп барышым . . . . . . . . . . . . . . . . 78
«Бик күрәсем килгәч сине...» . . . . . . . . . . . . . . . . 79
«Сине күрдем...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80
«Ярым булсаң, ярам гына булма...» . . . . . . . . . . . . 80
Сирень чәчәкләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81
«Мин бит сине, әй, хәләлем...» . . . . . . . . . . . . . . . 81
«Саубуллаштың: «Китәм бүген...» . . . . . . . . . . . . . 82
«Дөньяның бер үги кызы сыман...» . . . . . . . . . . . . 83

«Әй, бәгырь!..» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 83
Зәңгәр капка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
«Кешеләргә була җан аткан чак...» . . . . . . . . . . . . . . 85
Син идең — йолдызлар иленнән...» . . . . . . . . . . . . . . 86
Бул гына . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
Сүз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88
Ромашка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88
«Киләчәгем якты юл иде...» . . . . . . . . . . . . . . . . 89
«Ят кочакка тартыласың...» . . . . . . . . . . . . . . . . 89
«Син үзең дә беләсеңдер...» . . . . . . . . . . . . . . . . 90
«Минем сиңа атап язган...» . . . . . . . . . . . . . . . . 90
Көнләшерсең . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 91
«Безгә карап әйтте берәү...» . . . . . . . . . . . . . . . . 92

**IV. Поэма, балладалар**

Гармун моңы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 94
Сонлама . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 96
Читлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 99

Литературно-художественное издание

**Курбанова** Гульнур Равиловна

ЛОНО МЫСЛИ

Стихи

Казань. Татарское книжное издательство. 2006

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Корбанова** Гөлнур Равил кызы

УЕМНЫҢ КУЕНЫ

Шигырьләр

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *О.С.Сушкова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
*Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректоры *Р.Н.Шакирова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 7.08.2006. Форматы $70\times90^{1}/_{32}$. Офсет кәгазе. «Korinna» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 4,10. Шартлы буяу-оттиск 4,40. Нәшер-хисап табагы 3,67. Тиражы 1000д. Заказ 3-649.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы ААҖ. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.